**ГЛАВА АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район, с. Атабаево
Ул.Молодежная ,д. 1,
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
Яшьлэр урамы , 1нче йорт
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

---

**2024 елның 29 октябре** **3 номер**

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегенең Атабай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 7 ноябрендә 16.00 сәгатькә Лаеш муниципаль районының Атабай авыл җирлегенең Атабай торак пунктында Яшьләр урамы 1 й. адресы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Атабай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- торак пункт чикләрендә (Атабай торак пунктында Октябрь ур., Водопроводная ур. буенча)гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау,

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау буенча эшләр өчен түләүгә юллау

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Атабай авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Атабай**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы:_________________ И.Х.Мусин**